**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 17 сентябрендәге 2903 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 1 сентябрендәге 2781 номерлы «Татарстан Республикасы Рәисе инаугурациясе һәм Татарстан Республикасы Рәисенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юллама белән мөрәҗәгать итү тантанасын әзерләү һәм уздыру чорында Казан шәһәренең урам-юл челтәре буенча транспорт чаралары хәрәкәтен чикләү турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 маендагы 372 номерлы «Төбәк әһәмиятендәге яки муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә вакытлыча туктатып торуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында»гы карары нигезендә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 1 сентябрендәге 2781 номерлы «Татарстан Республикасы Рәисе инаугурациясе һәм Татарстан Республикасы Рәисенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юллама белән мөрәҗәгать итү тантанасын әзерләү һәм уздыру чорында Казан шәһәренең урам-юл челтәре буенча транспорт чаралары хәрәкәтен чикләү турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.1 пунктта «2025 елның 18 сентябрендә 23:00 сәгатьтән 2025 елның 19 сентябрендә 17:00 сәгатькә кадәр һәм 2025 елның 24 сентябрендә 23:00 сәгатьтән 2025 елның 25 сентябрендә 19:00 сәгатькә кадәр» сүзләрен «2025 елның 18 сентябрендә 19:00 сәгатьтән 2025 елның 19 сентябрендә 19:00 сәгатькә кадәр һәм 2025 елның 24 сентябрендә 19:00 сәгатьтән 2025 елның 25 сентябрендә 19:00 сәгатькә кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 1.1.1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бирергә:

«1.1.1. Пушкин урамында, Карл Маркс урамыннан Бассейн урамына кадәрге участокта (ике юнәлештә)»;

1.3. 1.1.2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бирергә:

«1.1.2. Театр урамында, Тельман урамыннан Дзержинский урамына кадәрге участокта (ике юнәлештә)».

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**